СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*9 сентябрь, 1998 ел.*
*ЧӘРШӘМБЕ*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 102 (8259)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

# ҖӘЙГЕ ЧЕЛЛӘЛӘРНЕ КӨТӘСЕ ЮК ИНДЕ

## *"Уңыш - 98" матбугат үзәге хәбәр итә*

**Сабан культураларыннан алты мең гектар чамасы мәйданда бодай һәм солыны гына суктырасы калып бара һәм аларның шактый өлеше орлыкка тәгаенләнгән мәйданнар булуын да истән чыгарырга ярамый. Уракны нигездә төгәлләгән хуҗалыклар шактый инде. Ә менә "Чирмешән", "Алга", "Татарстан", "Комбайн", шулай ук "Лесная Поляна" һәм нефтебаза ярдәмче хуҗалыкларында эш шактый әле. "Киекле" һәм Синдряков исемендәге хуҗалыкларда әлегә сабан бодаеның тулай җыемы иң күбе - меңәр тоннадан артыграк. Аларда бу культураның уңышы бер чамарак. Ә менә мичуринлылар бодайны нигездә уңыш югары булу исәбенә мең тонна чамасы җыеп алдылар инде. Солы уңышы буенча быел "Рассвет", Синдряков исемендәге һәм Хафизов исемендәге хуҗалыклар мактана алалар. Соңгысы ахыр чиктә борчак уңышы һәм аның тулай җыемы буенча да алга чыкты.**

**Көзге чәчүгә нокта куелгач, зур игътибарны туңга сөрү эшен тизләтүгә бирү зарурлыгы көн кебек ачык. Кичәге көнгә район буенча ул эш 23 мең гектардан артык мәйданда уздырылды. "Заря", "Дуслык", Мичурин исемендәге, "Родина" һәм "Сөлчә" хуҗалыкларында бу төр план 60 - 66 процентка башкарылды инде. Ә менә Кузнецов исемендәге һәм "Чирмешән" хуҗалыкларында сөреләсе мәйданнарның биштән бере генә, шикәр заводы, нефтебаза ярдәмче хуҗалыкларында, "Чулпан" һәм "Комбайн"да бары өчтән бере генә диярлек эшкәртелгән әле.**

**Терлек азыгы хәзерләүдә бүген иң мөһиме - кукуруз уруны тиз тоту. Аның силоска дигәнен "Алга"да, нефтебаза ярдәмче хуҗалыгында җыеп алдылар диярлек инде, шуңа күрә аларда бер шартлы терлеккә әзерләнгән азык берәмлегенең 20 центнердан артып китүе гаҗәп түгел. Ә менә кукуруз бик ишле булган "Татарстан", Хафизов исемендәге, Мичурин исемендәге, Кузнецов исемендәге, "Киекле" хуҗалыкларында аның тамырда утырганы да күп әле. "Агрохимсервис", шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларында, "Чирмешән"дә, "Комбайн"да да урылган мәйданнар күп түгел. Дөрес, аларның беренчесендә бүгенгә бер шартлы терлеккә әзерләнгән азык районда иң күбе - 37 центнерга җитеп килә инде. Ә калганнарында бу яктан бер дә мактанырлыклары юк әле.**

## КУНАКЛАР - БИЕКТАУДАН

***7 август көнне безгә Биектау районы хакимияте башлыгы Р.Г.Шәяхмәтов җитәкчелегендә делегация килде.***

***Кунакларның төп максаты терлекчелектә, аерым алганда дуңгызчылык тармагында алдынгы технологияләрне куллану тәҗрибәсен өйрәнү иде.***

***Танышу "Алга" КХАсының дуңгызчылык фермасыннан башланды. Биредә алар күптән түгел кертелгән натураль түләү тәртибе белән таныштылар, зур ремонт барышын карадылар. Аннан делегация М.Җәлил исемендәге КХАда чыгымнарга каршы механизмны гамәлдә күрде, "Өмет" кооперативының Урта Камышлы, "Агрокультура" кооперативларында дуңгыз асрау тәҗрибәсе белән танышты. "Агрокультура" һәм "Киекле"дә саву залларын карадылар, продукцияне пастеризацияләү һәм төрү җайланмасы белән кызыксындылар. Делегация Синдряков исемендәге КХАда фермаларны яңарту, дуңгызлар симертү буенча автомат - комплекста малларны симертү тәҗрибәсен карады.***

***Биектаулылар район терлекчелек тармагындагы үзгәрешләргә югары бәя бирделәр. берочтан шәһәрдә соңгы елларда калыккан Яшьләр үзәге, сәнгать йорты, бассейн, спортзал, аэропорт кебек объектларны да сокланып карадылар, үзләре өчен күп яңалык алуларын белдереп, канәгать киттеләр.***

## МӨҺИМ МӘСЬӘЛӘЛӘР ТИКШЕРЕЛДЕ

Дуңгызчылыкка игътибарны арттыруның зарурлыгы турында сөйләп тә торасы юк кебек. Әмма белеп алып барганда табышлы бу тармакка һәркайда да тиешле игътибар биреп җиткерелми әле. Хәзер менә малларны кыш туклыклы рационда тоту өчен катнаш силос салып калдырырга бик вакыт. Шуңа да шимбә көн хуҗалыкларның баш инженерлары, зоотехниклары һәм веттабиблары катнашында үткән семинар - киңәшмәдә сүз башлыча шушы тармакка кагылышлы мәсьәләләр турында булды. Анда катнашучылар "Өмет" агрофирмасының Кече Камышлыдагы һәм Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкның дуңгыз фермаларында чыгымнарга каршы технологиянең ничек гамәлгә ашырылуы белән таныштылар, берочтан, хуҗалыкларның беренчесендә мөгезле эре терлекләрне бәйләүсез асрау һәм саву залының эшен, икенчесендә савым көтүенең җәйге лагерьда ничек тотылуын карадылар, монда кукуруз һәм люцернадан өзелмәүче малларның рационы мулдан булуын белгәләп үттеләр.

РСУ ярдәмче хуҗалыгында дуңгыз абзарларын тирес транспортерларсыз эшләтүгә үзгәртеп корулары игътибарга лаек иде. Биредә дуңгызлар өчен катнаш силос салуны да технология таләпләрен үтәп алып баралар. Семинарның шул ук хуҗалыкта узган теоретик өлешендә район авыл хуҗалыгы һәм азык -төлек идарәсенең терлекчелек бүлеге башлыгы А.И.Ухваньков белгечләрнең игътибарын нәкъ менә шушыңа һәм малларны асрау, ашату, карау технологиясе таләпләрен тайпылышсыз үтәү зарурлыгына юнәлтте. Семинарда катнашып чыгыш ясаучылар - хакимият башлыгының беренче урынбасарлары - Ю.В.Терентьев һәм авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе башлыгы Ф.М.Дәүләтшин терлекчелектә сигез айлык эш нәтиҗәләренә җитди анализ ясап, бу тармакта эшне камилләштерү, терлек торакларын кышка әзерләүне ашыктыру, малларны эзлекле рәвештә кышкы торакларга кайтару буенча бурычларга киң тукталдылар.

## НӘКЪ ШУНДЫЙЛАР КИРӘК



Нәзир Зәйнуллинның шушы көннәрдә генә икенче улы туган. Исемен Нияз дип куярга сөйләшкәннәр.

- Тракторга өйрәтәм, авылдан беркая җибәрмим ди Нәзир,- дип елмаеп алды "Таң" КХАсының кооператив җитәкчесе Васыйл Сөнгатуллин. Күрәсең, Нәзирнең үз дәвамын шушында, туган җирендә күрәсе киләдер, үз һөнәрен дә өйрәтергә ниятлидер. Соңрак сайласа да, механизатор һөнәренә бар күңелен салды шул ул. Юкса, башта әтисе белән әнисе төсле үк терлекчелеккә эшкә килгән иде. Әтисе Закир ага белән әнисе Наҗия апа пенсия яшендә булсалар да һаман шул һөнәрләрендә, ә улларын ничектер техника үзенә тартты да куйды. Башта комбайнчы ярдәмчесе булып эшләде, аннан трактор ремонтлашты, ахыр чиктә үзенә дә трактор биреп куйдылар. Эшкә өйрәнүдә кооператив җитәкчесе Васыйл Сөнгатуллинның ярдәме зур булды. Хәзер исә үзе дә башка механизаторлар белән бер дәрәҗәдә диярлек белә инде техниканы. Ике ел инде КСК - 100 белән азык әзерләүдә эшли. Быел яз менә бу 160 гектарлы күкрәп утырган кукуруз кырының 150 гектарын үзе үк чәчте, аннан костер чәчүдә эшләде. Август ае кереп, авылның бар эше берьюлы өлгергәч, Нәзир янә эшнең иң җаваплы, җитди участогына басты - уҗым чәчте. Яшь механизатор димәссең, бүген аның хезмәт исәбендә 400 гектарлап чәчелгән уҗым исәпләнә. Аны хуҗалыкта җиренә җиткереп, ашлама белән чәчү шарт итеп куелган иде. Күп урынны арышка бирделәр, чәчүне "Эстафета Татарстана" дигән супер - элита орлык белән үткәрделәр.

Уҗым чәчү тәмамлануга, Нәзир янә тракторына КС - 2,6сын такты, янә кукуруз кырына юл алды. Хәзер менә биредә аны силоска салалар. Масса әйбәт, куәтле, бөртекләрнең өлгереше дә начар түгел. Шуңа таңлылар 30 - 40 гектарны бөртеккә алырга ниятләп торалар.

Шулай, авылда әле эшнең кызган чагы. Нәзиргә дә улы туган шатлыкны бәйрәм итеп торырга туры килмәде - эш көттергәнне яратмый. Бүген - иртәгә чөгендер плантацияләрендә эш башланырга тора. Нәзиргә БМ - 6 яфрак урдыргыч белән эшләргә дә туры килмәгәе әле быел. Анысы, эштән курка торган егет түгел ул Нәзир Зәйнуллин. Ә җир - ана нәкъ шундыйларны ярата.

**С.НУРУЛЛИНА.**

**Рәсемдә. Н.Зәйнуллин.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## *УРАК БАТЫРСЫЗ УЗМАС*

"Таң"нан **Вәгыйзь ГАЙФУЛЛИН** ДТ - 75 белән туңга сөрүдә көнгә 2,5 - 3әр норма үтәп, 400 гектардан артык җир эшкәртте инде.

***

"Киекле"дән **Вазыйх ХАЛИТОВның** КамАЗда кырдан ындырга ташыган ашлыгы 9 мең центнердан артып китте.

***

"Төрнәс"тән **Вячеслав ХРИСТОФОРОВ** К - 700 белән туңга сөрүдә икеярым норма үти, барлыгы 460 гектар җир эшкәртте.

## ЯЗ КӨНЕ НӘРСӘ ЧӘЧӘРБЕЗ?

***Саннарның беренче баганасы - 7нче сентябрьгә салынган сабан ашлыгы орлыгы ( төп һәм страховой фондларны кертеп центнерларда), икенчесе - планга карата процентларда.***

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| "Сөлчә" | 2650 | 98 | "Нефтебаза" ярд. хуҗ. | 1655 | 37 |
| "Илюткино" ярд. хуҗ. | 1970 | 98 | Кузнецов исем. | 1840 | 36 |
| "Игенче" | 2949 | 78 | "Заветы Ильича" | 1060 | 36 |
| "Дуслык" | 1328 | 78 | Хафизов исем. | 1617 | 27 |
| "Рассвет" | 4001 | 77 | "Кондырча" | 950 | 25 |
| "Төрнәс" | 3000 | 68 | "Чулпан" | 740 | 24 |
| РСУ ярд. хуҗ. | 2460 | 66 | Синдряков исем. | 2137 | 23 |
| "Комбайн" | 3000 | 61 | "Агрохимсервис" ярд.хуҗ. | 1070 | 22 |
| "Таң" | 1400 | 58 | "Чирмешән" | 880 | 21 |
| Мичурин исем. | 2960 | 52 | Шикәр заводы ярд. хуҗ. | 537 | 15 |
| "Үрнәк" | 2259 | 52 | "Киекле" | 990 | 13 |
| "Лесная Поляна" | 530 | 49 | "Алга" | 735 | 9 |
| М.Җәлил исем. | 920 | 42 | "Татарстан" | 410 | 4 |
| "Заря" | 1000 | 41 | | | |
| "Родина" | 844 | 40 | **Район буенча** | **45892** | **38** |


*Уҗым культураларын ниятләнгән кадәр үк булмаса да, былтырдан шактый гына күбрәк чәчеп калдыра алдык. Әмма киләсе елга да иң ишле мәйданнарны сабан культуралары алып торачак. Шуңа күрә сабан ашлыгы орлыкларын салып куюдан да мөһимрәк эш юк бүген. Дөрес, кыр эшләренең калганнары да, кем әйтмешли, арттан куып килә, әмма аларның кайсылары әле башлана гына, ә менә чәчүлек орлыкны салып кую һәр аяз сәгатьне сагалап торуны сорый. Кызганычка каршы, күпчелек хуҗалыкларда бу җәһәттән күп мөмкинлекләрне кулдан ычкындырдылар һәм моның нәтиҗәсе күз алдында. Әле бит чәчүлек материалның булган кадәресе дә һәркайда да тиешле кондициядә түгел һәм быелгы катлаулы шартларда орлыкны запас белән салып кую да зыян итмәс иде. Хуҗалыкара алмашу эшен дә язга калдырырга ярамый - теге яки бу культурадан чагыштырмача әйбәт уңыш алган хуҗалыкларда аны киләткә кертеп урнаштырганчы үзара алмашу үткәреп калырга ашыгырга кирәк.*

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Халыкка сәүдә хезмәте күрсәтүдәге уңышлары өчен "Эшчеләрне тәэмин итү идарәсе" чикләнгән җаваплылыктагы җәмгыятьнең Нурлат эшчеләрне тәэмин итү бүлеге башлыгы **Вәсилә Нурлыгаян кызы ХУҖИНАга "Татарстан Республикасының атказанган сәүдә хезмәткәре"** дигән мактаулы исем бирелде.

## Эзләнү юлында

# НУРЛАТНЫҢ ҮЗ ТЕГЕРМӘНЕ



***Нурлат - Октябрь элеваторында тегермән булдыру нияте күптәннән яши иде инде. Ни дисәң дә, башта бөртекне җыю, аннан комбинатларга - Казанга, Бөгелмәгә, Чаллыга озату, шуннан соң янә аны он итепҗыеп алу торган саен кесәгә ныграк суга иде. Әйтик, 1 тонна бодайны Бөгелмәгә озату гына да 26 сум 80 тиенгә төшә. Әгәр Бөгелмәдән 1 тонна онны 1957 сум белән җибәрсәләр, шуңа тимер юл бәясе, төяү, бушату чыгымнарына киткән 6 процентны өстәсәк, сату бәясе 2500 сумга җитә дә куя иде. Мондый бәя кемне канәгатьләндерсен? Шуңа соңгы ике елда элеватор район хакимияте ярдәме белән бу эшкә чынлап торып алына. Иң әүвәл, тегермән урнаштыру өчен бина - янкорма төзиләр. Түбән Новгородтан (нәкъ тегермәннәр иленнән!) җитештерү куәте сәгатенә 1 тонна продукциягә исәпләнгән тегермән алалар, аны Новгород осталары үзләре үк монтажлыйлар һәм быелның 28 августында - ТР Премьер - министры Р.Н.Миннеханов килгән көнне алар беренче оннан тәүге икмәкне пешереп, олы кунакны каршыларга чыгалар.***

Әлбәттә, башлангыч чор өйрәнү чоры була әле. Хәзер инде тегермән проект куәтенә чыгып бара. Коллектив 3 кешедән тора, өлкән мастер Илгизәр Миншакирович Төхфәтуллин - элек катнаш азык заводы директоры булган кеше, оештыру сәләте дә, грамоталыгы да җитәрлек. Бүген - иртәгә эшне өч сменада оештырырга ниятлиләр.

Шулай итеп, элеватор коллективы күптәнге хыялына ирешә. Шулай да, тегермән аларга нәрсә бирә соң?


- Икътисадый файда сизелерлек булачак. Бердән, 1 тонна онның үзкыйммәте 1892 сум чыга, ул читтән килгән он бәясеннән 30 процентка арзанрак булачак, - ди элеватор директоры Ә.Н.Миназов. Ә бу үзе үк ары таба күп мөмкинлекләргә юл ача. Бердән, бирелгән фонд буенча сату оешмаларына - азык комбинаты, ипи заводына продукция озатачак. Арзанлы продукция алар күңеленә дә хуш килергә тиеш. Икенчедән, моңа кадәр элеватор үз ихтыяҗлары өчен икмәк пешерә иде. Коллектив киләчәктә аны киңәйтергә, үз пекарнясында пешергән икмәкне үзе үк сатарга ниятләп тора. Ары таба токмач, макарон әйберләре җитештерү уйлары да юк түгел. Тегермән югары, беренче сортлы оннар һәм манный ярмасы чыгара. Соңгысын сату шулай ук начар булмаска тиеш. Әле моннан тыш халыкка тегермән хезмәте күрсәтүне дә кертергә ниятта торалар. Кыскасы, тегермәнгә эш җитәрлек күренә.

-Әгәр тегермән тәүлеккә 5 - 6 тонна продукция чыгара икән, ул үз - үзен тиз аклаячак,- ди Әхмәтнәкыйп Нурмиевич һәм икътисадый дәлилләр китерә. Әлбәттә, чын хуҗа санарга тиеш. Быел элеватор җитештерүне киңәйтү, камилләштерү максатында шактый чыгым түкте. Шул ук тегермәнне бастыру, җибәрү өчен генә дә 1 млн. 283 мең сум капитал салу тотылды, моннан тыш элеваторда ашлык киптерүне газга җайлау өчен дә 650 мең сум чыгым китте. Әмма хуҗалар боларның икеләтә, өчләтә экономия булып кайтасына нык ышаналар. Хәзер менә котельняларын тулысынча газга күчерү уе - мәшәкатендә яшиләр: проект ясала, эчке яңартулар бара. Финанс кыенлыгы шартларында шундый зур мәшәкатьләрне хәл иткән коллективны ничек инде алга карап яшәми дисең? Шуңа эшчеләр дә хезмәт хакы бирүнең тоткарлануын сабырлык белән кабул иткәннәр. Бүгенге чыгымнарның үзләренең киләчәге хакына башкарылуын аңлаганнар. Инде бу мәсьәләдә дә акрынлап режимга төшеп киләләр.

Менә шулай, бүгенге яңалыклар элеваторның киләчәгенә тагын да зуррак перспективалар ача, аңа базар шартларында үз икътисадын сакларга нигез вәгъдә итә. Ә бу - бик зур нәрсә!

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Рәсемдә: Нурлат элеваторы тегермәнендә.**



**Н.АЗИЗОВ фотомонтажы.**

# ЕЛАУР СУЛАГАЕ

***Борчаны дагалаган Тула Сулагае турында мифны хәтерлисезме? Шул заманнан Сулагай сүзе ("Левша") сул кул белән эшләүче генә түгел, ә гаҗәеп осталыкка ия сирәк талант символы итеп, баш хәрефтән языла торган тутыкмас образ булarak хәтергә сеңеп калган.***

Клементий Николаевич Охотников белән очрашып сөйләшкәч, шул образ хәтергә килде. Шундый ук җор сүзлелек, шундый ук үткенлек, осталыгы да җитәрлек. Куш син аңа бүген корыч борчаны дагаларга, мөгаен, югалып калмас, җаен табар иде. Өстәвенә, ул да сулагай - бөтен эш кораллары сул кул белән эшләргә җайланган. Агаебыз шул кораллар белән бөтен кирәк - яракны үзе ясап тора. Ишекләрме, тәрәзә рамнарымы? - рәхим ит, бер дигәнен ясап бирә Клементий дәдәгез. Ә, сезгә көрәк кирәкмени? Анысын да булдыра. Әллә кое бозралары эзләвегезме? Һм - м, уйлап карарга була. Юк, сез аңа әле тимер чиләк ясарга да заказ бирә аласыз. Әнә нинди һәйбәт итеп ясый ул аларны: бар рәвеше - нәкъ заводта эшләнгәнчә. Әле яхшырак та, ник дисәң, Охотников чиләк авызын бөкләгәндә корыч чыбык куеп калдыра, нәтиҗәдә чиләк тиз генә ямьшәйми, кыегаймый. Шуңа аның чиләкләренә заказ күп. Үткән ел "Знамя Октября" хуҗалыгына гына да 75 чиләк ясады, әле аннан тыш "Илюткино"дан да эшләтеп алдылар шундый чиләкләрне. Рәхәтләнгәннәрдер савучылар җиңел, уңайлы чиләкләргә. Әнә бит Клементий дәдәнең карчыгы Дарья Михайловна да сүз саен әйтеп тора: "Синең чиләкләреңнән дә иплесе юк", ди.

Колхозга ясап биргән көрәкләрен дә, кешеләр заказ биреп эшләткән рамнарны, ишекләрне дә ошаталар. Үз йортындагы һәр тактаны, һәр агачны үзе какты, үзе эшләде ул. Шуңа Кемеровода яшәүче улы Юрийның 8 яшьлек кызы - агайның оныгы бабасына хат язган: "Яз җитүгә, безгә кунакка кил. Яңа өебезгә ишек яңаклары куярсың",- дигән. Һәй, барыр, бик барыр иде Клементий Николаевич йорт салып ятучы улы янына, булышыр, төзешер иде! Заманасы башка шул хәзер, исәнлеге дә - башкача. Ярый инде, авылда яшәүче кызларына булыша алды.

Аларның өйләре зур түгел, әмма булдыклы хуҗа кулы һәр вак - төяктә дә сизелә. Ике бүлмә арасындагы ишек бизәкләп ясалган. Тәрәзәләрен күрегез әле: урам яктагы рам эченнән, өй ягыннан ике катлы итеп табаклы пыяла кисеп куйган. Пыяла шундый тигез, тыгыз итеп утыра - тузан да керми, җил дә куркыныч түгел, кышларын тәрәзә дә туңмый икән.

Абзар - кура тирәсенә чыксаң, шырпы тартмасы төсле тигезлек белән утын өелгән, абзар эченә җәелгән идән - чип - чиста. 64 яшьлек Охотниковлар ничек өлгерәләр икән барысына да?

- Мин эшсез торсам авырый башлыйм,- ди агай үзе. Гомер буе РУСта монтер, мәктәптә инструктор, хуҗалык эшләре мөдире, кочегар булып эшләгән, пенсиягә чыккач яшь чагында Самарада училищеда өйрәнгән һөнәрчелек белән ныгытып шөгыльләнә башлаган. Агач эше, тимер хезмәте дисеңме - һәммәсен белә. Әле бит кран - балканы да ремонтлый, су кудыруда да эшли. Тракторын да йөртә, машинасын да... Тик менә эш коралын гына калдырыр кеше булмаганга эче поша. Аның сул кулга көйләнгән коралларын теләсә кем куллана алмас бит әле!

Хәзерге замананың бер яхшы ягы бар ичмаса, диләр картлар, белгән эшең белән шөгыльләнә аласың. Юкса, 75 нче елларда бер кызык хәлгә дучар булган икән агаебыз. Кое өчен бозралар ясый башлый, коесын да казып - корып бирергә булышкалый. Шуның белән азрак акча эшлим дигәндә, килеп штраф салып китмәсеннәрме үзенә! Шуннан тик кенә утырырга ант иткән була.

Әлбәттә инде, антын бозуны гөнаһка санамый. Кеше һөнәргә ия икән - нигә дип белгәнен яшерергә, күмәргә тиеш? Авылдашлары Клементий Николаевич йортыннан һәр көнне шакылдау, кисү, ышкылау тавышлары ишетәләр дә сөенеп куялар: димәк, Елаур сулагае исән - сау, тагын нәрсәләр ясый. Әллә тагын корыч борча дагаларга җыенамы?..

**С.НУРУЛЛИНА.**

**Елаур авылы.**

*Бәхәсле хат*

# АВЫЛ БИТ УЛ САБЫЙ БАЛА КЕБЕК

Аяк астындагы туфрактан башланган бу кадерле туган якның һәр күренеше ямьле, күңелгә якын. Җырларга салып җырланган туган яктан да изге, аннан да кадерле җир бармы икән?! Туган ягым Яңа Иглай авылы булса да, тормыш мине Зирекле белән бәйләде. Моннан биш ел элек мәктәптә эшләп, КДПУга укырга да шул авылдан киттем.

Кайткан җиремә авыл шактый үзгәрешләр кичергән. Авылдагы шәхси йортлар көн дә матурлана,кирпеч белән тышлана. Зиреклелеләрнең һәммәсе дә табигый газдан файдалана. Авылга атнага дүрт тапкыр автобус йөри башлау да - халыкка олы куаныч. Зиреклелеләрне борчыган иң зур проблема - юллар, авыл урамындагы юллар. Урамда аз гына яңгыр явып үттеме - чыгарлык түгел. Җәяүлеләр генә түгел, атлар, тракторлар, җиңел машиналар да бик авыр йөриләр. Ә инде мәчеткә йөрүче картлар зарын ишетү йөрәкне әрнетә. Мәчеткә намаз укырга көнгә берничә килү - алар өчен зур газап. Кичләрен яшьләребезнең матур киенеп, түфлиләрдән клубка барасы килә, укытучылар башка авыллардагы коллегаларына сокланып, без дә шулай матур, биек үкчәле түфлиләрдән кайчан йөрербез икән дип хыялланалар.

Безгә авыл эчендә асфальт юллар кирәкми, ул киләчәк хыял. Безгә юлларны күтәреп, таш салдырсалар да бик җитә. Һич югында мәчеткә, бабаларыбызга рәхим - хөрмәт йөзеннән булса да юллар ясалсын иде.

Икенче проблеманы да язып үтми булмас. Бу көннәрдә район буенча колхозларны берләштерү бара. Моңда уйлап җиткерелмәгән бер нәрсә бар, дигән уйда зиреклелеләр. Мәсәлән, "Үрнәк" колхозын да берләштереп, ике авылны - Зирекле, Биляр Озероны бергә кушып куйдылар. Ничек инде саф татар авылын рус яки чуваш авыллары белән кушарга? Бу милләтләрнең милли бәйрәмнәре, дини йолалары берничек тә бергә була алмый. Колхоз бер булгач, бәйрәме дә бергә үтә бит аның. Шул ук дини бәйрәмебез - ураза көнне рус, чуваш кешеләре рәхәтләнеп эчә. Шуңа хәзер безнең авыл яшьләре дә аларга тартыла башлады. Нигә әле безне элекке колхоздашыбыз булган Фома авылына кушмаска?

Бу хатны районыбыз җитәкчелеге дә укысын, үтенечебезгә колак салсын иде. Без бит шул районда яшәячәк яшьләр. Димәк, күпмедер дәрәҗәдә районыбызның киләчәге дә безнең кулда.

**Хәлим ӘЛИМОВ.**

**Зирекле авылы.**

***Газетабызның былелгы 4 сентябрь санындагы "Шатлыкны бүлешсәң - ул арта" дигән язмада "547 нче ПМК осталары быел яздан башлап 31 август төненә кадәр гаять зур күләмдә эш башкардылар",- дигән юллар бар иде. Бу урында: "1нче ПМК осталары",- дип укуыгызны сорыйбыз, төгәлсезлек өчен гафу үтенәбез.***

# ИЗГЕЛЕК ҺӘМ ИГЕЛЕК ТУРЫНДА

Поликарп Герасимович Кузьмин - Урта Камышлыдан, гомерлек механизатор, хәзер пенсиядә инде, 82 яшендә. Дингә ышана, шуңа күрә элек Биляр Озерога йөргән чиркәүгә, хәзер Нурлатка килә. Дин халыкны бары яхшылыкка гына өйрәтә, сабырлыкка чакыра дип саный. Әле менә чиркәүне җиһазлау өчен финанс кытлыгы турында ишеткәч, пенсиясеннән җыеп иске акча белән миллион сум китереп тапшырган. Район газетасын укучылар П.Г. Кузьминның моннан элек чиркәү төзелешенә дә миллион сум акча биргәнлеге турында укыган булганнардыр.

Поликарп Герасимович үзенең бу гамәле башкаларга да яхшы үрнәк булыр, шәхеснең һәм православие чиркәвенең ныгуына булышлык итәр дип ышана. Эчкерсез күңелле бу игелекле кешенең үзенә дә тазалык - саулык һәм озын гомер телисе килә.

**В.ВЛАДИМИРОВ.**

# «МИНЕМ ПРОФИЛАКТОРИЙДАГЫ ҖӘЕМ»

***Балаларның җәйге ялы тәмамланды. Мәктәпләр аларның шаулы тавышлары, шуклыклары белән тулды. Хәтерегездәме, иң озын каникулдан кайтып, сагынылган парталар артына утыруга ук укытучы "Мин җәйне ничек үткәрдем" дигән темага инша яки хикәя яздыра иде? Кем әбисендә авылда яшәгән, кемдер лагерьга барган яки диңгез буйларында йөргән. Өеннән беркая чыкмыйча, көннәрен гадәттәгечә уздырганнар да бар, билгеле.***

***Ә менә "Нурлатнефтеразведка" ның санаторий - профилакториенда ял һәм дәва алучыларның язар сүзләре бик күп. Хәер, 21 көн буена андагы бай программадан, туклыклы, төрле менюдан һәм, әлбәттә, җылы итәгатьле мөнәсәбәттән алган тәэсирләре бер иншага гына сыярлык та түгел. Профилакторийның бүлмәләре әле берничә көн элек кенә балалар тавышыннан бушап калды: дүртенче агымда ял иткән һәм дәва алган 60лап мәктәп укучысы бу кунакчыл йорт белән хушлашты. Бу язма шулар хакында.***

Газета укучының игътибарын санаторий - профилакторий турындагы хикәя белән җәлеп итүнең башка сәбәбе дә бар: Нурлатта иң беренче булып зәвык белән төзелгән һәм бүген дә әле шул матурлыгын җуймаган бинага бу көннәрдә 15 ел тула. Нефть эзләүчеләр үз эшчеләренең сәламәтлеген ныгытуны моннан күпкә алданрак, иске бинада ук башлыйлар: санасаң, шул елларда меңләгән кеше анда ял һәм дәва алган. Ә менә балалар ялы шул яңа бинада 5 ел элек оештырыла башлый. Табигый ки, җаваплы эшкә алына җитәкчелек: олылар белән чагыштырганда, балаларга дәва биреп кенә калмыйча, ялларын оештырырга, шөгыль табарга, тәрбия моментларын да куллану, димәк, педагогик кадрларны эшкә җәлеп итү дә кирәк бит, ягъни өстәмә чыгымнар сметасын төзү таләп ителә дигән сүз. Ниятләнгән эш төрле яклап тирәнтен өйрәнелгәннән соң, 50 урынлы профилакторийга бер төркем җыела. "Ата - аналарга ошады, әлбәттә,- дип сөйли "ТН - ННР"ның профком рәисе Г.Ш.Сөләйманов. - Алар үтенече буенча агымнарны елдан - ел арттырып, быел 4кә җиткердек. Уку елының соңгы көннәреннән - 28 майдан 28 августка кадәр барлыгы 244 бала биредә ял итеп, сәламәтлеген ныгытты, яңа уку елына көч туплады. Ял итәргә теләк белдерүчеләр бик күп иде. Ләкин юллама иң беренче чиратта балалар консультациясе күрсәтмәсе нигезендә бүленә, ягъни авырулары булган, сәламәтлеге какшый төшкән балаларга дәвалау мөмкинлеге тудырыла".


## ЯЛ

Профилакторийда көннең беренче яртысы балаларның актив ялыннан - мәдәни - агарту чараларында катнашудан гыйбарәт. Программа администрация һәм тәрбиячеләр белән берлектә төзелә. Беренче көн өчәр, башлыча, икешәр урынлы җайлы, җыйнак бүлмәләрне балаларның үз рухындагыча, күзаллавындагыча бизәүдән башлана. Шунда ук иң оригиналь, иң чиста палата исеменә конкурс игълан ителә. Һәм шунда инде балаларның бай фантазиясе эшкә җигелә: "Нечкәбилләр", "Каскадерлар", "Каратистлар"... Аннары үзләре ял итә торган урын - профилакторийның абруен күтәрү ноталары чагылган девизлар, җырлар һәм башкалар әзерләнә. Мәдәни программа ("Талантлар эзлибез", КВН, әкиятләрне сәхнәләштерү, балалар сабантуе, рәсемнәр, "Оста куллар" конкурслары һәм башкалар) һәркайсының сәләтен ачарга, үзен күрсәтергә ирек бирә. Хәрәкәтчән уеннар, шәһәр стадионында спорт уеннары, актив физик күнегүләрнең дә балаларга файдасы аз түгел, билгеле.

Һәр агымда дүрт тәрбияче, башлыча, алар ярдәмче интернат - мәктәптән. Мәсәлән, Г.Л.Вязьмина, М.Т.Давыдова, О.В.Бурнашевскаялар икешәр, өчәр агымда эшләп балалар белән тиз уртак тел табып, җылы мөнәсәбәт урнаштыралар.

Саубуллашу көнендә балалар гомуми линейкада ихлас рәхмәтләрен җиткерәләр. Калын журналга яраткан тәрбиячеләре, тәмле ашлар белән сыйлаучыларга карата шигырьләр язып калдыралар, ә тәрбиячеләр киләчәктә ялны тагын да яхшырту, камилләштерү буенча тәкъдимнәрен кертәләр.







Рәсемнәрдә: профилакторийда ял һәм дәва алучылар; аларга хезмәт күрсәтүче өлкәннәр.

Н.АЗИЗОВ фотолары.

## ДӘВАЛАУ

Көннең икенче яртысы дәвалауга багышлана. Урнашуга ук, һәркемнең диагнозы нигезендә индивидуаль дәвалау билгеләнә. Витаминнар, төрле препаратлар бирелә, шифалы үләннәрдән ясалган төнәтмәләр белән авыз куышлыгын чайкау да һәркем өчен мәҗбүри. Яңа гына төзелгән ләм белән дәвалау корпусында ванна залы, 4 төрле душ, ләм белән аппликация, массаж, сәламәтлек ванналары - кыскасы, җаның - тәнең ни тели - һәммәсе бар. Ә балаларга шулардан иң ошаганы душ икән. Физиологик дәвалау ысулларыннан тыш диетик туклануга да зур игътибар бирелә. Бусы балаларга ошап бетми, билгеле (бу файдалы туклануны олыларның да күбесе өнәми). Профилакторийның баш врачы А.И. Юнысов шуңа бәйле бер кызыклы очракны искә төшерә: кичке диетик аштан соң ашханәнең бер урындыгыннан кечерәк кенә плакат табып алалар. "Диетик азык кирәкми, йогурт, банан кирәк безгә", диелгән була анда. Бу очрак әлеге продуктлар булмавыннан түгел, әлбәттә: яшелчә, җиләк - җимеш алларыннан өзелми, аны Самарадан махсус кайтарталар. Туклану монда көненә 4 тапкыр оештырылган һәм аның сыйфаты да яхшы.

## КЕМ ТҮЛИ?

Профилакторийда, нигездә, предприятиедә эшләүчеләрнең балаларына урын бирелә. Юллама 1675 сум тора, аның 92 сумын гына ата - аналар түли, калганы "Нурлатнефтеразведка" ОООсының социаль страхование фондына күчерелгән акчаларыннан каплана. Башка предприятиеләрдән юллама сорап мөрәҗәгать итүчеләр күп, бу очракта шул предприятие бюджеты исәбеннән акча күчерелә.

4 агымда барлыгы 100мең сум чамасы акча тотылган. Предприятие җитәкчелеге гамәлләреннән аңлашылганча, хезмәткәрләр һәм аларның сәламәтлекләрен саклау һәм ныгытуга җәмгыять киләчәктә дә акча кызганмаячак, алай гына түгел, өстәмә чыгымнар тотып, санаторий - профилакторий хезмәтен тагын да яхшырту, камилләштерүгә көч куелачак.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

## Кичәге почтадан

# ШЕФЛАРЫБЫЗ

Яңа уку елы башланды. Безнеке кебек катлаулы микрорайонда зур шәһәр тормышы белән яшәүче яшьләргә тирән белем, заманга яраклы тәрбия бирү кебек үтә четрекле проблемаларны хәл итү белән бергә, тавык та чүпләп бетерә алмаслык көндәлек мәшәкатьләр дә килеп баса. Ике катлы зур бинадагы төп хуҗалык эшләреннән тыш балаларны кайнар аш белән тәэмин итү, җылылык, яктылык, төзеклек, уку әсбаплары, күргәзмә материал...

Чиләк - себерке, кадак алырлык та мөмкинлеге булмаган мәктәпкә бүгенге финанс кытлыгы чорында кайсы якка егылырга, кемгә таянырга? Ярый әле шефларыбыз - "Нурлатнефть" НГДУсы бар. Киңәш - уңашка да алар янына барабыз, ярдәм сорап та нефтьчеләргә егылабыз. Әле менә быелгы ремонт чорында да шефларыбыз булмаса, мәктәптә зур күләмдә ремонт эшләре башкара алмаган булыр идек. Теплицаны капиталь ремонтлауга керешкәч, цемент, торба бирделәр. ЦКПРС аркылы юнәткән блоклы тәрәзә рамнары, стена өчен буяу да бик зур ярдәм булды безгә. Автодело кабинетын автомобиль узеллары һәм агрегатлар белән җиһазлауда исә УТТ саллы ярдәм күрсәтте. Эстетика төркеменең булышлыгы да зур булды. Идарәнең СМЦ, УПРП, БПО кебек подразделениеләре дә ярдәм сорап мөрәҗәгать иткәндә кире борганнары булмады. Быел без мәктәпләрне яңа уку елына хәзерләү буенча район смотр - конкурсында II урынга чыкканбыз икән, монда шефларыбызның өлеше бихисап.

Бүгенге авыр көндә үзебезне терәкле итеп тоюю эшкә дәрт, киләчәк көнгә өмет, оптимизм уята. Бик рәхмәт шефларыбызга. Шуңа да без идарә начальнигы М.М.Хуҗин, аның якын ярдәмчеләре - цех начальниклары И.Г.Вәлиуллин, Ш.Г.Яһудин, Н.В.Мостафин, Г.И.Шәйхетдинов, И.М.Фәхретдинов, А.А.Собольков, урынбасары Д.Н.Вәлиев, профсоюз комитеты рәисе О.Н.Лизунов һ.б., гомумән, тулаем нефтьчеләр коллективын һөнәри бәйрәмнәре белән кайнар котлап, аларга бетмәс - төкәнмәс энергия, эшләрендә уңышлар, сәламәтлек, иминлек телибез. Ә без, үз чиратыбызда, мәгърур нефтьче һөнәрен хөрмәт итәрлек һәм барлык тармакларда да уңышлы эшләрлек буын хәзерләүне бурыч итеп куярбыз.

**Р.ГИНЯЕВА,**
**Нурлат шәһәренең 4нче урта мәктәбе директоры.**

